МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **№ 215/2-пр**

**16.06.2023** **Казан шәһәре**

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2019 елның 1 июлендәге 135/2-пр номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы һәм «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге 68-ПУ номерлы Указы нигезендә **БОЕРАМ:**

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 1 июлендәге 135/2-пр номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2021 елның 13 декабрендәге 352/2-пр номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс кандидатларның дәүләт граждан хезмәте (алга таба - граждан хезмәте) вазыйфасын биләүгә һөнәри дәрәҗәсен бәяләүдән, граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен аларның квалификация таләпләренә туры килүен тикшерүдән һәм кандидатлар арасыннан булган гражданны яисә граждан хезмәткәрен шундый бәяләү һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп кую өчен өчен ачыклаудан гыйбарәт.»;

1.3 пунктта «министр карары буенча» сүзләрен «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр карары буенча» сүзләренә алыштырырга;

1.8 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«граждан хезмәте вазыйфаларының кече төркеменә керүче граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә министр карары буенча;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«федераль законнарда каралган башка очракларда.».

2.4 пунктның 2.4.1 пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре һәм кадрлар эшләре департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алыштырырга;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Граждан (граждан хезмәткәре) түбәндәге очракларда конкурста катнашуга кертелми:

а) һөнәри белем дәрәҗәсенә, гражданлык хезмәте яисә белгечлеге буенча эш стажына, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләренә туры килмәүгә бәйле;

б) белгечлеге буенча квалификация таләпләренә, әзерлек юнәлешенә (белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең киңәйтелгән төркемнәренә), яңа һөнәргә өйрәнүнең өстәмә һөнәри программасын үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификациягә (граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләре белән шундый таләпләр каралган очракта) туры килмәүгә бәйле;

в) граждан хезмәтенә урнашуга һәм аны башкаруга булган чикләүләргә һәм дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләргә бәйле.»;

3.4 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«нотариаль яисә хезмәт (эш) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган белем һәм (яисә) квалификация турында документлар күчермәләре, шулай ук гражданның теләге буенча гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турында документлар күчермәләре»;

4.5 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданның (граждан хезмәткәренең) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләренә, граждан хезмәте буенча яисә белгечлеге буенча эш

стажына, әзерлек юнәлешенә, һөнәри дәрәҗәсенә, шулай ук министрның тиешле карары булганда - белгечлегенә, белгечлек юнәлешенә (белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең киңәйтелгән төркеменә), яңа һөнәри белем алуның өстәмә һөнәри программасын үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификациягә туры килүен тикшерүне.»;

4.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс уздырганда конкурс комиссиясе кандидатларны алар үзләре тапшырган белем һәм (яисә) квалификация турындагы, граждан хезмәтендә яисә башка дәүләт хезмәтендә эшләве турындагы документлар нигезендә, шулай ук, кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләүнең федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килми торган ысулларын кулланып, кара-каршы әңгәмә коруны, анкеталауны, биләүгә (резервка кертүгә) кандидатлар дәгъва кыла торган граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервы вазыйфасы) буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча реферат язуны яисә тест үткәрүне дә кертеп, конкурс процедуралары нигезендә бәяли.»;

4.12 пунктның 4.12.2 пунктчасында:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алыштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тест уздыру Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан раслана торган тест уздыру методикасы нигезендә башкарыла».

2. Әлеге боерыкның үтәлешен үзем тикшереп торам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр М.А. Җәббаров